


Россия  Эчке  эшләр министрлыгынын Саранск шәһәр округы буенча 3 нче ОПга 19 яшьлек жирле кеше мөрәжәгать иткән: анардан 27 100 сум урлау турында әйткән. Яшь кеше хәбәр иткәнчә, 9 сентябрьдә ул интернет сайтында интим характердагы түләүле хезмәтләр күрсәтү турында белдерү тапкан. Гариза бирүче күрсәтелгән номер буенча шалтыраткан.      Администратор кыз белән очрашу 2 мен сум күләмендә алдан түләү күчерелгәннән сон гына була ала, дип анлаткан. Зыян күрүче тормышка ашыра, әмма шуннан сон 5 меннән артык күләмдә иминият түләргә кирәк була. Жирле кеше бу шартларны да үтәгән. Аннары администратор түләү үтмәгән, шуна бәйле рәвештә түләүне кабатларга кирәк, дип белдергән.
Зыян күрүче акча күчергән һәм жинаятьче финанс операциясен кабатларга кирәклеген анлаткан, чонки акча техник озеклек аркасында кермәгән, дигән. Нәтижәдә бер сәгать дәвамында торле уйлап чыгарылган сылтаулар астында жинаятьче зыян күрүченен 27 мен сумнан артык акчасын урлаган.
Аннары эшнен нәрсә икәнлеген анлагач, кызнын килүен котеп тә тормыйча, гариза бирүче полициягә мөрәжәгать иткән. Хәзерге вакытта жинаятьчеләрне эзләүгә юнәлдерелгән тиешле чаралар үткәрелә.